**Татарстан Республикасы**
**Югары Ослан муниципаль районы Советы**
**Карар № 35-391, 05.07 2018**

**“Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы” муниципаль казна оешмасы турында Кагыйдәнамәне раслау турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында ”06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасының ”Татарстан Республикасында җирле үзидарәләр турында” 28.07.2004 ел,№ 45-ТРЗ, Югары Ослан муниципаль районы Уставына туры китереп,

**Югары Ослан муниципаль районы советы**
**Карар кылды:**

1. Кушымта №1 белән килешенеп “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы” муниципаль казна оешмасы турында Кагыйдәнамәне расларга.

2. Көчен югалткан дип санарга:

- Югары Ослан муниципаль районы советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы турында Кагыйдәнамә ”, 30 декабрь, 2005ел, №4-32, карары;
- Югары Ослан муниципаль районы советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы турында Кагыйдәнамәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”, 4 апрель 2012ел, №25-240 карары;
- Югары Ослан муниципаль районы советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы турында Кагыйдәнамәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”, 28 гыйнвар, 2013ел, № 34-348 карары.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокук мәгълумат рәсми порталында һәм Югары Ослан муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Югары Ослан муниципаль районы Советының икътисад үсеше, экология, табигать байлыклары һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә тапшырырга.

**Совет рәисе,**
**Югары Ослан**
**муниципаль районы башлыгы** **М.Г.Зиатдинов**

Югары Ослан муниципаль районы Советы
№ 9-81, 14.03 2016 карарына
Кушымта №1

**“Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы” муниципаль казна оешмасы турында**

**Кагыйдәнамә**

## I.Гомуми кагыйдәнамәләр.

1. “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы” муниципаль казна оешмасы (алда- Палата) гамәлдә булган закончалык һәм муниципаль норматив хокукый актлар билгеләгән күләмдә Югары Ослан муниципаль районында муниципаль мөлкәт белән идарә итү, шул исәптән муниципаль район милеге булган акцияләр, хуҗалык оешмаларының устав капиталындагы кертем, кулланышта яки район карамагында булган җир кишәрлекләре белән идарә итү максатыннан оештырылган җирле үзидарәнең даими эшләүче органы булып тора.

2. Палата Югары Ослан районы муниципаль Советы (алда- Совет) тарафыннан муниципаль казна оешмасы формасында барлыкка килә.

3. Тулы атамасы: “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы” муниципаль казна оешмасы.

Кыскартылган атамасы: Югары Ослан муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы.

4. Палата юридик затларны теркәү закончалыгы билгеләгән тәртиптә дәүләт теркәлүе узган вакыттан юридик зат статусына ия.

5. Палата мөстәкыйль баланс, бюджет сметасы һәм билгеләнгән тәртиптә ачылган шәхси счёт, налог түләүчеләрнең идентификат номеры, мөһере, үзенең атамалары белән бланклар булдыра ала.

6. Палатаның урнашкан урыны: Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Югары Ослан авылы, Медгородок урамы, 21А йорты.

7. Палата Район Советы белән хисаплашырга тиеш.

8. Үзенең компетенциясе кысаларында кабул ителгән Палата карарлары билгеләнгән тәртиптә күрсәтмә, аның рәисе әмере килеш эшләнә.

9. Палата үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конситуциясе, Татарстан Республикасы Конститутциясе, федераль законнар, Татарстан Республиаксы законнары, Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Президенты боерыкнамәләре, Татарстан Республикасы территориясендә эшләп килгән норматив хокукый актлар, Югары Ослан муниципаль районы Уставы, Югары Ослан муниципаль районы җирле

үзидарәләре норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Кагыйдәнамәгә нигезләнә.

10. Палатаның төзелеше һәм штатлы расписаниесе муниципаль районның җирле үзидарә башкарма органнары хезмәткәрләренең эшчәнлеге өчен түләү фонды һәм күләме чигендә район Советы тарафыннан раслана.

11. Палата үз исеменнән башка юридик һәм физик затлар белән хокук бәйләнешенә керергә хокуклы.

12. Палата үз исеменнән федераль һәм республика законнары, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставы, муниципаль район җирле үзидарәләре норматив хокукый актлары, әлеге Кагыйдәнамә урнаштырган чикләрдә гражданлык әйләнешендә катнашырга, гражданлык һәм башка хокук һәм бурычларны тормышка ашырырга хокуклы.

13. Палата табыш китерә торган эшчәнлекне тормышка ашыра ала. Күрсәтелгән эшчәнлектән кергән табыш муниципаль район бюджетына керә.

14. Палата муниципаль район җирлегендә урнашкан җир кишәрлекләре һәм дәүләт объектларына кагылышлы Югары Ослан Хакимияте 2006 ел 1 гыйнварга кадәр кабул иткән килешүләр һәм карарлар буенча Югары Ослан Хакимиятенең хокуклы варисы булып тора.

15. Әлеге Кагыйдәнамәдә үз эченә районның муниципаль күчемле һәм күчемсез милеге (гамәлдәге закончалыкка яраклашкан торак һәм торак булмаган биналар, төзелеш корылмалары, җир кишәрлекләре һәм башка төр күчемсез мөлкәт) булган, тиешле хокуктагы муниципаль оешмаларга беркетелгән һәм беркетелмәгән, шулай ук башка мөлкәт, шул исәптән гамәлдәге закончалыкка туры килгән муниципаль милекнең хокук объекты булган мөлкәткә хокук муниципаль мөлкәт төшенчәсе кулланыла.

16. Әлеге Кагыйдәнамәне куллану максатыннан районның муниципаль милеге булган җирләр һәм җир кишәрлекләре, шулай ук муниципаль районның җирләрендә урнашкан җир кишәрлекләре , муниципаль районның җирле үзидарә оешмаларына караган җирләр җир һәм җир кишәрлеге булып аңланыла .

## II. Палатаның темасы һәм эшчәнлеге максатлары

17. Палатаның темасы һәм эшчәнлеге максатлары булып үзенең компетенцияләре кысаларында урындагы әһәмиятле сорауларны тормышка ашыру өлкәсендә идарә итү функцияләрен үтәү, шулай ук Югары Ослан муниципаль районы муниципаль милеге булган, муниципаль районның җирле үзидарә органнарының муниципаль хокук актлары билгеләгән закончалык урнаштырган тәртип буенча тапшырылган хокук, ягъни Югары Ослан муниципаль районы муниципаль милеге булган мөлкәт һәм мөлкәт хокукларына хуҗа булу, файдалану, куллану; муниципаль мөлкәтне нәтиҗәле һәм табышлы куллануны тәэмин итү; җирне һәм муниципаль мөлкәтне куллануны тикшерүне тәэмин итү.

18. Югары Ослан муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы җирле үзидарә органы буларак түбәндәге хокукларны тормышка ашыра:

- “Татарстан Республикасы Югары Ослан районы” муниципаль оешмасы исеменнән җир кишәрлекләре һәм муниципаль мөлкәткә хуҗа булу, аның белән идарә итү, аннан файдалану хокукын тормышка ашыра;

- “Татарстан Республикасы Югары Ослан районы” муниципаль оешмасы файдасына мөлкәтне, шул исәптән оешмаларны (мөлкәт комплекслары), акцияләр (өлешләр,пайлар), башка күчемле һәм күчемсез мөлкәтне сатучы һәм сатып алучы сыйфатында була ала;

- махсуслаштырылган оешмалар белән сәүдә үткәрү (конкурс, аукцион) турында килешү төзи;

- махсуслаштырылган оешмаларга билгеләнгән тәртиптә сату өчен хосусыйлаштырылган объектларыны тапшыра;

- муниципаль мөлкәтне арендалау турында килешү төзүгә хокуклы сатучы сыйфатында була ала;

- муниципаль милекнең исемлеген формалаштыра һәм алып бара, күчемсез объектларны муниципаль милеккә тапшыру турында документлар проектын эшли;

- муниципаль район территориясендә җир кишәрлекләре формалаштыруны тормышка ашыра;

- муниципаль мөлкәтне, шул исәптән федераль милеккә җир кишәрлекләрен, Татарстан Республикасы милкенә, башка муниципаль оешмалар милкенә һәм башка милек формаларына тапшыруны тормышка ашыра;

- җир кишәрлекләрен даими (вакыты чикләнмәгән) куллану хокукында муниципаль һәм дәүләт оешмаларына, җирле үзидарә органнарына һәм дәүләт властена тапшыруны тормышка ашыра;

- муниципаль мөлкәтне арендалау турында килешү төзи, шул исәптән аренда килешүе төзүгә хокукларны сату турында килешү төзи;

- гамәлдәге закончалык билгеләгән күләмдә муниципаль мөлкәтне оператив идарә итү һәм хуҗалык алып бару хокукында муниципаль оешмалар һәм муниципаль унитар хуҗалыкларга беркетә;

- билгеләнгән тәртиптә оператив идарә итү хокукы белән ныгытылган артык, кулланылмаган яки урынлы кулланылмаган мөлкәтне алуны тормышка ашыра;

- муниципаль казнаныкы булган муниципаль унитар хуҗалыкларга һәм муниципаль оешмаларга беркетелмәгән муниципаль мөлкәткә исәп – хисап алып бара;

- муниципаль оешмаларга һәм муниципаль унитар хуҗалыкларга беркетелгән муниципаль мөлкәтне, һәм башка муниципаль мөлкәтне күзәтүне, тәртип бозулар булса, гамәлдәге закончалык нигезендә тиешле чаралар күрә, шулай ук җир кишәрлекләрен тиешенчә куллану һәм саклауны күзәтүне тормышка ашыра;

- муниципаль районда җир төзү документларын раслау, җир төзү эшләрен башкару һәм халык алдында сервитутлар турында документлар әзерләүдә катнаша;

- Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру, куллану сораулары буенча муниципаль хокук актлары проектларын эшли;

- закончалык нигезендә хосусый милек иясенең авыл хуҗалыгына караган җир кишәрлеген сату турындагы хәбәрен карап чыга һәм җир кишәрлеген муниципаль милеккә сату турында карар кабул итә, яки сатуны кире кага;

- Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә җир кишәрлекләрен сатып ала, шул исәптән билгеләнгән тәртиптә муниципаль ихтыяҗ өчен тартып алган , һәм шулай ук муниципаль милеккә башка мөлкәтне сатып ала;

- "Авыл хуҗалыгына караган җирләр әйләнеше турында"Федераль законын, Татарстан Республикасы Җир кодексын күздә тотып, кирәк очракта тиешле гариза белән судка мөрәҗәгать итә;

- муниципаль мөлкәтне һәм җирне хосусыйлаштыру, куллануның законлы мәнфәгатьләрен һәм хокукларын яклау буенча суд, хокук саклау һәм башка вәкаләтле органнарга мөрәҗәгать итеп, юридик гәмәлләрне тормышка ашыра;

- муниципаль район территориясендә муниципаль җир тикшерүен тормышка ашыра;

- "Муниципаль һәм дәүләт кирәк –яракларын тәэмин итү өчен кулланылган ярдәм, эш, товарлар сатып алу өлкәсендәге контракт системасы турында" № 44-ФЗ законга яраштырып, муниципаль ихтыяҗ өчен товар белән тәэмин

итү , муниципаль милек белән идарә итүдә хезмәт күрсәтү буенча, шулай ук үз ихтыяҗлары өчен урынлы сорауларны чишүдә контрактлар төзүче муниципаль заказ бирүче сыйфатында катнаша;

- муниципаль районның законлы мәнфәгатьләрен , мөлкәт һәм башка хокукларын тормышка ашыру максатыннан мөлкәт һәм җир кишәрлекләрен бәяләүне оештыра;

- муниципаль милек белән идарә итү өлкәсендә муниципаль программалар һәм башка проектларга муниципаль заказ бирүче функцияләрен тормышка ашыра;

- муниципаль оешмалар һәм муниципаль унитар хуҗалыкларга күчемсез милек белән башкача идарә итү һәм читләштерү буенча килешү, шул исәптән залогка, арендага, мөлкәт кертемнәрен оешмаларның устав (склад) капиталына (фондына) кертү, шулай ук федераль закон, башка норматив хокук актлары яки оешма уставында билгеләнгән буенча вәкиллекләр ачырга һәм филиаллар төзергә, займ бирү белән бәйле, банк гарантияләрен алу, җаваплылык, бурычны кичектереп тору буенча килешү төзү, оешманың башка юридик затларда катнашырга, шулай ук гади

ширкәтләр килешүе төзүне, кызыксыну уяткан зур килешү төзелгән очракта килешү тәкъдим итә;

- Муниципаль унитар хуҗалыклар белән җәлеп ителгән чараларның күләмен һәм куллану юнәлешен килештерә;

- үзенең компетенцияләре кысаларында муниципаль милек объектларына инвентаризация үткәрүне билгели һәм башкара;

- төп фондны, шулай ук хуҗалык, муниципаль оешмалар һәм муниципаль унитар хуҗалыкларда оператив идарә итү карамагында булган тукталган яки төзелеп бетмәгән төзелеш объектларына тотылган чыгымнарны сызып ташлауны күзәтә;

- Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына яраклаштырып муниципаль районның устав капиталындагы өлеше белән акционер җәмгыятьләрнең төпсезлеге турында гамәлне башкаруны һәм аның үтәлешен күзәтүне тәэмин итә;

- федераль законнарга яраклаштырып муниципаль унитар хуҗалыкларны, акционер җәмгыятьләрен муниципаль районның устав капиталындагы өлеше белән судсыз юкка чыгару гамәлен оештыра;

- муниципаль унитар хуҗалыкларны, акционер җәмгыятьләрен муниципаль районның устав капиталындагы өлеше белән банкротлыкка чыгармау , кризиска каршы тору белән идарә итү чаралары эшли һәм тормышка ашыра;

- Башкарма комитетның җирләрне арендага яки милек итеп бирү, (даими) күп вакыт бушлай куллануга бирү, җир кишәрлекләренә халык алдында сервитутлар билгеләү турында, җир кишәрлекләрен арендага бирү һәм сату-алу турында килешү төзү, бушлай куллану, шулай ук муниципаль кирәк- яраклары өчен тоту турында җирләрне тартып алу турында хокукый актлар проектларын әзерли;

- сату- алу килешүе һәм җир кишәрлекләрен арендага бирүнең әһәмиятле һәм башка шарларын билгели ;

- аренда өчен түләү исәбен алып бара;

- сату- алу килешүе һәм җир кишәрлекләрен арендага бирүдән кергән акчаны тикшерүне тормышка ашыра;

- күчемсез милеккә, шул исәптән җир кишәрлекләре, алар белән килешүгә, муниципаль милек хокукларын дәүләт рәсмиләштерүе өчен кирәкле гамәлләрне тормышка ашыра;

- муниципаль район исеменнән законга яраклаштырып акционер оешмаларның (хуҗалык оешмалары)акционерлары (катнашучы), муниципаль милек булган акцияләр (устав капиталындагы өлеш) хокукларын тормышка ашыра;

- муниципаль унитар хуҗалыкларны һәм башка объектларны хосусыйлаштыруны әзерләү, хосусыйлаштырылучы муниципаль мөлкәтне бәяләүне үткәрүне оештыру, хосусыйлаштырылучы оешмаларның устав капиталы күләмен билгеләү һәм бәясен раслау чараларын тормышка ашыра;

- муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыручы прогнозлы планга (программа) яраклаштырып муниципаль мөлкәтне (акцияләр, өлешләр,

пайлар, оешмаларның мөлкәтле комплексларын), шул исәптән кертем сыйфатында хуҗалык оешмаларының устав капиталына кертү, хосусыйлаштыру турында, муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турында, хосусыйлаштыру планын раслау турында карарлар кабул итә;

- массакүләм мәгълүмат чараларында муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында, шулай ук хосусыйлаштыру килешүләре нәтиҗәләре турында хәбәрләр бастыруны тәэмин итә;

- раслау өчен билгеләнгән тәртиптә муниципаль район җирләрен инвентаризацияләү буенча муниципаль программаны эшли һәм таныштыра;

- федераль законнарга яраклаштырып, төзелеш регламенты каралмаган яки билгеләнмәгән җир кишәрлекләренең кулланылышын билгели;

- билгеләнгән тәртиптә Башкарма комитетына,район Советына,Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Министрлыгына муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру нәтиҗәләре турында хисап тотуны әзерли һәм таныштыра;

- муниципаль торак фондын хосусыйлаштыруны башкара;

- тиешле җирле үзидарә органнарына билгеләнгән тәртиптә хосусыйлаштырудан кергән акча турында алдан әйтә, шул исәптән җир ресурслары турында мәгълуматларны эшкәртә һәм таныштыра;

- җирле бюджетка муниципаль милектә булган акционер җәмгыятьләрнең (башка хуҗалык оешмаларының устав капиталындагы өлешләргә керем) акцияләре өчен дивидентларны күчерүне тикшерүне башкара һәм чаралар күрә, дивидентларның оптималь күләмен билгели;

- җирле бюджетка чиста керем өлешен күчерүне оештыра;

- Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнарына яраклаштырып, муниципаль районның җирле үзидарә органнарына тапшырылган җир ресурслары һәм дәүләт мөлкәте белән идарә итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкәләтлекләрен башкара;

- конкурс нигезендә экспертларны, шулай ук специальләшкән юридик, аудит, риелтор һәм башка оешмаларны җәлеп итә;

- билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә конгресслар, конференцияләр, семинарлар, күргәзмәләр һәм башка чааралар оештыра;

- гражданнарны кабул итүне оештыра, гражданнарның телдән һәм язмача мөрәҗәгатьләрен үз вакытында һәм тулы итеп тикшерә, алар буенча карарлар кабул итә һәм законда билгеләнгән вакыт эчендә гариза бирүчегә җавап кайтара;

- муниципаль контракт төземичә башкарылган сатып алулар турында исемлек алып бара;

- социаль ориентлашкан коммерцияле булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтүне оештыруда катнаша;

- закончалыкка, Югары Ослан муниципаль районның җирле үзидарә органнарынаың хокук актларына яраклаштырып башка вәкалатләрне тормышка ашыра.

IV. Палатаның хокуклары һәм бурычлары.

19. Палата хокуклы:

- үз исеменнән килешү төзи, законга яраклаштылган тәртиптә хосусый һәм хосусый булмаган хокукларны ала , бурычлар ала, судта дәгъвачы һәм җавапчы була;

- акционерлар җыелышына  һәм устав капиталында муниципаль оешма өлеше булган акционерлар оешмасының директорлар советының көн тәртибенә киңәшләрне җибәрә, аларның үтәлешен тикшерә;

- Татарстан Республикасы дәүләт органнарыннан, муниципаль район җирлегендә урнашкан  муниципаль унитар оешмалардан һәм  муниципаль оешмалардан, җирле үзидарә органнарыннан, башка оешмалардан, Палатага йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәк булган закончалык белән яраклаштырган икътисад, статастик, хокук һәм башка мәгълуматларны бушлай ала;

- закончалык белән яраклаштырган тәртиптә бушлай “Татарстан Республикасы буенча кадастр һәм картография, дәүләт регистрация Федераль хезмәтенең Федераль кадастр Палатасы”Федераль бюджет оешмасы филиалыннан, Федераль хезмәтнең дәүләт регистрациясе Идарәсеннән, Татарстан Республикасы кадастр һәм картографиясеннән  җир кишәрлекләренә һәм күчемсез милек объектларына  хокуклары турындагы, муниципаль милектә булган җирләр белән идарә итү өчен кирәк булган башка мәгълуматны  соратып алдыра; муниципаль мөлкәтне исәпләп тора һәм аның исемлеген алып бара;

- муниципаль район исеменнән муниципаль районны яклап муниципаль милекне хосусыйлаштыру, аның белән идарә итү мәсьәләләре буенча судка дәгъва(гариза) белән мөрәҗәгать итә, шул исәптән:

муниципаль милекне хосусыйлаштыру, аның белән идарә итү килешүләрен көчсез дип таба;

муниципаль унитар оешмаларның кеременең бер өлешен түләтә;

муниципаль мөлкәтне ,шул исәптән  җир кишәрлекләрен куллану өчен аренда һәм башка түләүләр түләтә;

физик һәм юридик затларның нигезсез эшләре белән  муниципаль оешмага китергән зыяннарын каплата;

закончалык белән яраклаштырган очракларда башка сораулар буенча мөрәҗәгать итә;

- закончалык белән яраклаштырган очракта һәм тәртиптә хуҗалык алып бару хокукында, оператив, ышанычлы идарә итүче оешмаларга беркетелгән муниципаль мөлкәтне тартып ала;

- дәүләт власте органнарына муниципаль районның җирле үзидарәләре органнарының норматив хокук акт проектларын, методик материалларны, киңәшләрне, җир һәм мөлкәт өлкәсендәге бәйләнешләр буенча күрсәтмәләрне эшләүдә бушлай методик һәм практик ярдәм күрсәтү буенча сораулар белән мөрәҗәгать итә; Татарстан Республикасы дәүләт

милке объектларын муниципаль район милкенә тапшыру турындагы тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итә.

20.Палата бурычлы:

- үзенең компетенцияләре кысаларында муниципаль районның экономик мәнфәгатьләренә зыян китерүне булдырмыйча җир ресурслары һәм муниципаль мөлкәт белән нәтиҗәле идарә итергә;

- муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштырган вакытта закон бозылган очракта суд тәртибендә муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турындагы килешүне өзү, закончалык белән яраклаштырып һәм муниципаль мөлкәтне сату-алу килешүенә яраклаштырып зыянны капларга һәм башка чаралар куллану турында дәгъва белдерә;

- гаеплеләрне җавапка тарту турында карар кабул итү өчен, билгеләнгән тәртиптә хокук саклау органнарына муниципаль мөлкәтне тоту өлкәснедә, кулланганда закон бозылган очраклар турындагы, җир мөнәсәбәтләре белән бәйле сораулар белән материалларны җибәрә;

- закончалык белән яраклаштырып Татарстан Республикасы дәүләт власте органнарына, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетына, Югары Ослан муниципаль районы Советына үзенең эшчәнлеге турында мәгълумат һәм хисап тапшыра.

V.Палата эшчәнлеген оештыру һәм аның белән җитәкчелек итү

21. Палата эшчәнлеге белән закончалык , әлеге Кагыйдәнамә белән яраклаштырып бердәм башлангыч принциплары кысаларында, Югары Ослан муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе (алда- Рәис) җитәкчелек итә.

22. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе вазифаларына буш муниципаль хезмәт вазифаларын башкару өчен үткәрелгән конкурс нәтиҗәләре буенча район Башлыгы боерыкнамәсе белән билгеләнә.

23. Палата рәисе муниципаль район җирле үзидарәсендә хезмәттәге зат булып тора.

24. Палата рәисе Палата эшчәнлеген оештыру һәм алып бару буенча түбәндәге функцияләрне үти:

- Палата, аның мәнфәгатьләрендә барлыкка килгән максатларны саклауны тәэмин итә;

- Палата исеменнән ышанычнамәдән башка эш йөртә, аның мәнфәгатьләрен судларда, бөтен оешмаларда яклый;

- Палата хезмәткәрләре үтәргә тиешле әмерләр, боерыкнамәләр чыгара, Палата белгечләре арасында вазифаларны бүлә һәм хезмәткәрләрнең вазифа күрсәтмәләрен, башка эчке документларны раслый;

- Палата исеменнән закончалык белән, әлеге Кагыйдәнамә белән ,башка муниципаль хокук актларына, контракт һәм мөлкәтне ныгыту турында килешүгә яраклаштырып, килешүләр, контрактлар төзи,ышанычнамәләр бирә, башка гамәлләр башкара һәм аларның үтәлешен тәэмин итә;

- район Советы раслауына хезмәт хакы фонды кысаларында Палатаның төзелешен һәм штатлы расписаниесен тәкъдим итә;

- банкларда хисап счёты һәм башка счётлар ача һәм яба, алар буенча эш йөртә,финанс документларына кул куя;

- гамәлдәге закончалыкка яраклаштырып Палата хезмәткәрләренә карата мактау куллана һәм шелтә белдерә;

- үзенең компетенцияләре кысаларында күрсәтмәләр һәм боерыкнамәләр бирә;

- Палатага тапшырылган мөлкәтне исәптә тоту һәм саклауны оештыра;

- Палата хезмәткәрләрен эшкә ала һәм эштән азат итә;

- гражданнарны кабул итүне алып бара, аларның шикаятьләрен, гаризаларын,тәкъдимнәрен карый;

- Палата функцияләренә кергән башка эшләрне башкара.

## VI. Палатаның мөлкәте һәм финанслары

25. Палата әлеге Кагыйдәнамә белән билгеләнгән максатларга ирешү өчен бюджет сметасы буенча бүлеп бирелгән акчаны һәм мөлкәтне куллана.

26. Палата эшчәнлеген оештыруга кирәкле мөлкәт, оператив идарә итү хокукында аңа беркетелә.

Палата гамәлдәге закончалыкка, әлеге Кагыдәнамәгә яраклаштырып эшчәнлек максатларында үзенә беркетелгән мөлкәткә карата куллану хокукына ия була.

27. Палата үзенең йөкләмәләре буенча кулланышында булган акча өчен җавап бирә. Ул җитмәгән очракта аның йөкләмәсе буенча субсидиар җаваплылыкны “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы”муниципаль оешмасы үз өстенә ала.

28. Палатаның мөлкәте һәм байлыгы аның балансында чагылыш таба һәм гамәлдәге закончалыкка яраклаштырып файдаланыла.

29. Хосусый милек иясе артык, тиешенчә кулланылмаган мөлкәтне тартып алырга хаклы һәм үзенең ихтыярында эш йөртә ала.

30. Палата эшчәнлеген финанслау чыгымнарның еллык смета кысаларында җирле үзидарә органнарын тоту өчен бүлеп бирелгән акчага, җирле бюджет хисабына башкарыла.

## VII.Палата хезмәткәрләрен социаль яклау

31. Палата эшчеләре муниципаль хезмәткәрләр булып торалар.

32. Палата эшчеләренең социаль гарантияләре гамәлдәге муниципаль хезмәтләр турында закончалыкка яраклаштырып булдырыла.

## VIII. Әлеге Кагыйдәнамәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү

33. Әлеге Кагыйдәнамәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү Татарстан Республикасы Югары Ослан районы Советы карары белән башкарыла.

**Совет рәисе,**
**Югары Ослан**
**Муниципаль районы башлыгы** **М.Г.Зиатдинов**